РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Г.Тукая ул., д. 7, с. Шадки, 422096
тел.: (84360) 53-7-12,
E-mail: Sdk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Г.Тукай ур., 7 нче йорт, Шәтке авылы, 422096
тел.: (84360) 53-7-12,
E-mail: Sdk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94319624 ОГРН 1061675011914 ИНН/КПП 1619004482/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 9**

**КАРАР**
**« 25 » март 2025 ел.**

## Татарстан Республикасы Теләче районы Шәтке авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын (этләрне) йөртү өчен урыннар билгеләү турында

Теләче районы прокуратурасының 2025 елның 13 февралендәге Исорг-20920037-170-25/-20920037 номерлы хокукый документ проектын карап, тиешле чисталыкны һәм тәртипне саклап калу, хайваннарга карата гуманлы мөнәсәбәтне тәэмин итү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы; «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законнар; Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Регионнар министрлыгының 2011 елның 27 гыйнварындагы 613 номерлы «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча нормалар һәм кагыйдәләр эшләү буенча методик киңәшләрне раслау турында» боерыгы нигезендә, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын (этләрне) йөртү өчен урыннарны кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Йорт хайванын йөрткәндә, күрү сәләте буенча инвалидны озата баручы эттән тыш, түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

2.1. автомобиль юлының машина юлы киселешендә, лифтларда һәм күпфатирлы йортларның гомуми файдаланудагы биналарында, мондый йортларның ишегалларында, балалар һәм спорт мәйданчыкларында хайванның ирекле, контрольсез хәрәкәт итү мөмкинлеген булдырмаска;

2.2. гомуми файдаланудагы урыннарда һәм территорияләрдә хайваннар эшчәнлеге продуктларын җыюны тәэмин итәргә;

2.3. йорт хайванын әлеге карар белән рөхсәт ителгән урыннардан читкә йөртергә чыгармаска;

2.4. этләрне торак биналардан (йортлардан) һәм изоляцияләнгән территорияләрдән

гомуми ишегалларына һәм урамга чыгарырга:

- декоратив һәм ау токымнарын - кыска бәйдә;
- потенциаль куркыныч этләр; биеклеге 35 сантиметрдан артып киткән этләр - кыска бәйдә, борынчык белән (өч айга кадәр көчекләрдән тыш);

2.5. этләрне моның өчен махсус билгеләнгән мәйданчыкта 6.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр йөртергә. Әгәр дә мәйданчык киртәләнгән булса, потенциаль куркыныч этләрдән тыш, этләрне бәйсез һәм борынчыксыз йөртү рөхсәт ителә;

2.6. этләрне башка вакытта йөрткәндә аларның хуҗалары тынлыкны тәэмин итү чараларын күрергә тиеш;

3. Тыела:

3.1. йорт хайваннарының балалар һәм спорт мәйданчыкларында, мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, мәгариф һәм сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт учреждениеләре территорияләрендә, су коену урыннарында (пляжларда), кешеләрнең күпләп ял итү урыннарында һәм җирле үзидарә органнары билгеләгән башка территорияләрдә йөрүе, шулай ук аларның азык - төлек кибетләре һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре биналарында булуы; әлеге пунктның гамәлдә булуы озата баручы этләргә кагылмый.

3.2. этләрнең үзлегеннән йөрүе;

3.3. йорт хайваннарын тотканда, подъездларның, баскычларның, шулай ук балалар, мәктәп, спорт мәйданчыкларының, массакүләм ял итү урыннарының, җәяүлеләр юлларының һәм машина юлларының пычрануы.

3.4. этләрне наркотик, алкогольле яки башка токсик исерек хәлдә кешеләргә, хокукка сәләтсез дип танылган кешеләргә йөртү тыела, ә потенциаль куркыныч этләрне 14 яшьтән кечерәк балаларга йөртү тыела.

4. Йорт хайваннарын урамда йөртүне гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтенең сакланышын мәҗбүри тәэмин итү шарты белән гамәлгә ашырырга.
5. Әлеге карар авыл хуҗалыгы йорт хайваннарын тотуга кагылмый.
6. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
7. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Ф.Г.Кадыйров

Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 25 март 2025 ел № 9 нчы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын (этләрне) йөртү урыннары

| № т/б | Торак пункт | Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урын |
|---|---|---|
| 1 | Шәтке авылы | көнъяк-көнчыгыш юнәлеше, Бохар урамыннан 50 метр ераклыкта; |
| 2 | Югары Мирәтәк авылы | Үзәк урамнын Михайловлар, Николаевлар йорты каршындагы коры елга янәшәсендә |
| 3 | Олы Мирәтәк авылы | Көнъяк-көнчыгыш юнәлеше, Яшьләр урамыннан 50 метр ераклыкта |

Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән территория территориянең чикләрен (күләмен) күрсәтеп һәм «Йорт хайваннарын йөртү урыны» дигән язу һәм схема белән билгеләнә:

